**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ РАЙОН СОВЕТЫ**
**(IV чакырылыш)**

**КАРАР**
IV чакырылыш чираттан тыш утырышы

29 октябрь 2021 ел № 84 Урыссу ш. т. п.

Ютазы муниципаль районы Ютазы
район Советы һәм Башкарма комитеты
структурасына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 37 статьясына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 25 статьясына, «Татарстан Республикасы муниципаль районы җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең структурасын формалаштыру һәм штат санын билгеләү буенча методик рекомендацияләр турында» 09.12.2020 ел, № ПР-187 "Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Советы" Ассоциациясе Президиумы карарына таянып, Ютазы муниципаль районы Уставының 44 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Ютазы район Советы карар кабул итә:

1. Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты структурасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
- «баш белгеч (тәрҗемәче)» штат берәмлеген структурадан чыгарырга;
- «торак сәясәте бүлеге началнигы» штат берәмлеген структурадан чыгарырга;
- «инфраструктура үсеше бүлеге начальнигы урынбасары”  штат берәмлеген структурага кертергә.
2. Татарстан Республикасы Ютазы район Советы структурасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
- «баш белгеч (тәрҗемәче)» штат берәмлеген булдырырга һәм аны юридик бүлек составына кертергә.
Әлеге карар 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Ютазы муниципаль районы
Башлыгы вазыйфаларын башкаручы З.В. Ильясов.